**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлегенең Адав-Толымбай авылында гражданнар җыены карары**

13 ноябрь 2025 ел № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Адав-Толымбай авыл җирлегенең Адав-Толымбай авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2026 елда Адав-Толымбай авыл җирлегенең Адав-Толымбай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;

- урамнарны яктыртуны җайлау;

-Адав-Толымбай авылында торак пункт территориясен төзекләндерү (кышкы чорда юлларны кардан чистарту, җәй көне территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, тракторчыга хезмәт күрсәтү өчен килешү буенча түләү; мәдәният йорты янында койма урнаштыру).

3. Җыен нәтиҗәләрен Адав-Толымбай авыл җирлегенең Адав-Толымбай авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Адав-Толымбай авыл җирлеге башлыгы _________ А.Ф.Әхмәтҗанов

Гражданнар җыены секретаре _________ Г.Ш.Насертдинова